Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы

Питрәч авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 14

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башлыгының «Питрәч авылында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 8 октябрендәге 137 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 60 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проектны гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башлыгының «Питрәч авылында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (алга таба – Проект) (кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. гавами тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 1 декабрендә, 11.00 сәгатьтә Питрәч муниципаль районы Советының кече залында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет ур., 18 й.;

2.3. авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч ав., Совет ур., 18 й. адресы буенча (дүшәмбе-җомга 8-00 дән

12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

2.4. Питрәч авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында 2023 елның 28 ноябрендә срок белән бер көнгә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет ур., 18 йортында (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты белән 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) проектның демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештырырга.

3. Комиссиягә:

3.1. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәсен әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов